ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЛМАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

“04” март 2022 ел Калмаш авылы №1

“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлегенең Калмаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Калмаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 14 мартында 18.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Калмаш авылы Каенлы, Дуслык,, Салимгараев, Чияле, Тынычлык, Кояшлы, Күл буе, Төн як, Лазурная, Җиңүгә 70 ел, Фатих Амирхан, Чәчкәле, Муса Җәлил, Якут Метшин, Яшьләр, Төзүчеләр, Урманлы, Болынлы, Басу урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2022 елның 15 мартында 16.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Калмаш авылы Зөфәр Галиев урамында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2022 елның 15 мартында 18.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Калмаш авылы Гагарин, Зөфәр Галиев, Үзәк, Советлар, Яңа, Сәйдәш, Тукай урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә
4. Калмаш авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе халык җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча башкарырга
5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлегенең 24.11.2021 елда кабул ителгән 1 номерлы Калмаш авыл җирлегендә халык җыены нәтиҗәләре турында карарга (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә килешәсезме?:
"Калмаш авылында тукталыш павильоны урнаштыру «сүзләренә» Калмаш авылында тукталыш павильоны һәм тукталыш павильоны өчен мәйданчык урнаштыру" сүзләрен өстәргә

“ӘЙЕ” “ЮК”.

6. Җыенның өч этабын да түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Калмаш авылы, Центральная урамы, 32 нче йорт, «Яшьлек»мәдәният йорты.
7. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
8. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

9. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

10. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Калмаш авыл җирлеге Башлыгы Р.К.Габдуллина